Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

25 октябрь, 2023 ел № 31

Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Ильинский пос. торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 164 номерлы (2021 елның 13 декабрендәге 39 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Богородский авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Богородский авыл җирлегендә Ильинский поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Ильинский поселогында. Халык җыенын 2 этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 11 ноябрьдә 10.00 сәгатьтә кибет янында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: 422777, РТ, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Ильинский п., Урман ур., 33 й. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Заозерная, Колодезная, Кривая, Лесная, Огородная, Полевая, Придорожная, Северная урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабын 2023 елның 11 ноябрьдә 11.00 сәгатьтә кибет янында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: 422777, РТ, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Ильинский п., Урман ур., 33 й. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Осиновая, Сосновая, Дубовая, Центральная урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2024 елда Богородский авыл җирлеге Ильинский поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- балалар мәйданчыгын төзү һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Богородский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов